## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2022 елның 18 ноябре, № _2_

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Дружба торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Ләке авыл җирлеге көне Петрлар өчен призлар, бүләкләр сатып алу;

- Дружба торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу».

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _ _ _ _ _ _ Шәрипова Л. И.